*Исправления не допускаются*

**Итоговый балл** ________ ___________________ **Шифр** _____________

(подпись председателя жюри)

**Межрегиональная предметная олимпиада Казанского федерального университета
по предмету «Татарский язык»
Очный тур
2016-2017 учебный год
11 класс**

**I. Татар һәм рус телендәге сүзләрне Б графасында цифрлар куеп тәңгәлләштерегез.** / Напишите в графу Б цифры соответствия слов на татарском и русском языках (10 баллов).

| А | | Б | |
|---|---|---|---|
| 1 | ятим | | скромный |
| 2 | сәфәр | | сугроб |
| 3 | күпчелек | | претензия |
| 4 | көрт | | войско |
| 5 | дәгъва | | путешествие |
| 6 | баһадир | | отличие |
| 7 | ялкын | | пламя |
| 8 | тыйнак | | большинство |
| 9 | аерма | | сирота |
| 10 | гаскәр | | богатырь |

**II. Күп нокталар урынына тиешле хәрефләрне куегыз** / Вместо многоточий вставьте нужные буквы (5 баллов).

1) Дә... апасы белән автобуста а...ылларына кайтып килеше иде Әнвәрнең. 2) Көн кызу, ...әммәсе дә әлсерәшеп, йок...мсырап утыралар. 3) Кинәт алгы урындыкта утырган кыз чәчрәп сикереп торд..., кычкырып ...ибәрде хәтт.... 4) Янындагы өлкән яш...тәге бер абый авырып киткән икән. 5) Пассажирлар ...галып калды, ыгы-зыгы башланды. 6) Әнвәр сизмәде дә, апасы кай арада тор...п киткән дә теге абыйга ашыгыч ярдәм күрсәтә башлаган. *(Л.Н.Гыймадиевадан)*

**III. Бирелгән тексттан гарәп-фарсы алынмаларын язып алыгыз.** / Выпишите из текста арабо-персидские заимствования. (10 баллов)

Шигъри телебез Тукай белән ачылган. Пушкин дөньясына Тукай теле ачкыч булды – Пушкинны иң әүвәл татарча укыдык.

Балачак сокланулары аша ачыла башлаган Пушкин дәрьясын еллар үткән саен, үрелеп буй җитә алган чаклы күрә барам; Пушкин галәмен тану гомер буе дәвам итәр.

Хәзер Пушкинны үз газиз телемдә укып хозурланам. (*Ш. Галиевтан)*

_______________________________________________________________

_______________________________________________________________

_______________________________________________________________

**IV. Җөмләдәге тыныш билгеләренең ни өчен куелуын аңлатыгыз.** / Объясните, по каким правилам поставлены знаки препинания в предложении. (10 баллов)

Шуңа да игътибар итәргә кирәк:(1) Кол Гали дә,(2) Мөхәммәдьяр да "сабыр" сүзендә,(3) язмышка буйсынып,(4) пассивлык күрсәтүне түгел,(5) бәлки, (6) эшнең җаен белеп,(7)нигезле хәлдә гамәл итүне күздә тота.(8) (М. Госмановтан)

**1)**______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

**2)**______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

**3)**______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

**4)**______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

**5)**______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

**6)**______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

**7)**______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

**8)**______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

**V. Башваткычны чишегез.** / Решите кроссворд. (15 баллов)



**Горизонталь буенча:**

**1.** Сүзнең бер кисәген башкаларыннан аерып әйтү. 4. Сүз эчендә сузык авазларның бер-берсенә охшашлануы. 7. Телнең билгеле бер территориядә таралган формасы. 8. Телдә барлыкка килә торган яңа сүзләр. 10. Сүзнең мәгънәгә ия булган иң кечкенә кисәге. 11. Сүзнең кисәкләргә бүленми торган, төп мәгънәне белдергән өлеше. 13. Сыйфат ачыклап килгән исем. 14. Ике яки берничә кешенең үзара сөйләшүе.

**Вертикаль буенча:**

2. Сүзне бер телдән икенче телгә кисәкләп тәрҗемә итеп ясалган сүз. 3. Нинди дә булса күренешнең, төшенчәнең искергән атамасы. 5. Бер үк яки якын мәгънәле сүзләр. 6. Телнең чисталыгы өчен алынмаларга каршы көрәш. 9. Бер атаманың икенче атамага охшашлыгы нигезендә барлыкка килгән күчерелмә мәгънә төре. 12. Сузыкларның кыскаруы яисә төшеп калуы. 15. Башка телдән алынган сүз.

**VI. Равил Фәйзуллин шигыре килеп чыгарлык итеп, калын хәреф белән бирелгән сүзләрне җәя эчендә соралган рәвештә төрләндерегез һәм бер-берсенә бәйләгез** /Воспользуясь подсказками в скобках, склоняйте и свяжите выделенные слова таким образом, чтобы в итоге получилось четверостишие Равиля Файзуллина. (15 баллов).

1 юл) **киләчәк-** (*исем, берлек санда, иялек килешендә*), **баш-** (*исем, 3 зат берлек сандагы тартым белән төрләнгән, баш килештә*), **бүгенге-** (*нисби сыйфат, исемләшеп, урын-вакыт килеше кушымчасын алган*).

2 юл) **нинди** (*сорау алмашлыгы*), **шатлык** (ясалма *исем, берлек санда, баш килештә*), **картлык** (ясалма *исем, берлек санда, баш килештә*), **көн**- (исем, 2 зат берлек сандагы тартым белән төрләнгән, урын-вакыт килешендә)

3 юл) **онык-** (*исем,күплектә, 2 зат тартым белән төрләнгән, баш килештә*), **син-** (2 *зат алмашлыгы, юнәлеш килешендә*), **рәхмәт** (*исем, берлек санда, баш килештә*), **әйт-** (*шарт фигыль, 3 зат берлектә*)

4 юл) **матур** (асыл *сыйфат, төп дәрәҗәдә*), **ит-** (*1 формалы хәл фигыль, төп юнәлештә*), **туган** (*үткән заман сыйфат фигыль*), **тел-** (исем, 2 зат берлек сандагы тартым белән төрләнгән, урын-вакыт килешендә)

____________________________________________

____________________________________________

____________________________________________

____________________________________________

**VII. Татар теленең орфографиясе һәм аның принциплары турында языгыз** / Напишите об орфографии татарского языка и о его принципах (15 баллов).

____________________________________________

____________________________________________

____________________________________________

____________________________________________

____________________________________________

____________________________________________

____________________________________________

____________________________________________

____________________________________________

____________________________________________

____________________________________________

____________________________________________

____________________________________________

____________________________________________

____________________________________________

____________________________________________

____________________________________________

____________________________________________

____________________________________________

____________________________________________

____________________________________________

____________________________________________

____________________________________________

____________________________________________

**VIII. Татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукай турында "Очты дөнья читлегеннән тарсынып күңлем кошы" дигән темага 90 сүздән ким булмаган инша языгыз. Фикерләрегезне дәлилләп, кимендә 2 мисал китерегез. /**Напишите сочинение (не менее из 90 слов) на тему "Улетела птица души моей, презрев этот бренный мир" о великом татарском поэте Габдулле Тукай. Приведите не менее 2 довода-примера (20 баллов)

*Исправления не допускаются*

# ОТВЕТЫ

**I. Татар һәм рус телендәге сүзләрне Б графасында цифрлар куеп тәңгәлләштерегез. /** Напишите в графу Б цифры соответствия слов на татарском и русском языках (10 баллов).

| А | | Б | |
|---|---|---|---|
| 1 | ятим | 8 | скромный |
| 2 | сәфәр | 4 | сугроб |
| 3 | күпчелек | 5 | претензия |
| 4 | көрт | 10 | войско |
| 5 | дәгъва | 2 | путешествие |
| 6 | баһадир | 9 | отличие |
| 7 | ялкын | 7 | пламя |
| 8 | тыйнак | 3 | большинство |
| 9 | аерма | 1 | сирота |
| 10 | гаскәр | 6 | богатырь |

**II. Күп нокталар урынына тиешле хәрефләрне куегыз** / Вместо многоточий вставьте нужные буквы (5 баллов).

**Җавап:** Дәү апасы белән автобуста авылларына кайтып килеше иде Әнвәрнең. Көн кызу, һәммәсе дә әлсерәшеп, йокымсырап утыралар. Кинәт алгы урындыкта утырган кыз чәчрәп сикереп торды, кычкырып җибәрде хәтта. Янындагы өлкән яшьтәге бер абый авырып киткән икән. Пассажирлар югалып калды, ыгы-зыгы башланды. Әнвәр сизмәде дә, апасы кай арада торып киткән дә теге абыйга ашыгыч ярдәм күрсәтә башлаган *(Гыймадиева Л.Н. буенча).*

*Дөрес билгеләнгән һәр хәреф - 0,5 б.*

**III. Бирелгән тексттан гарәп-фарсы алынмаларын язып алыгыз.** / Выпишите из текста арабо-персидские заимствования. (10 баллов)

Шигъри телебез Тукай белән ачылган. Пушкин дөньясына Тукай теле ачкыч булды – Пушкинны иң әүвәл татарча укыдык.

Балачак соклanулары аша ачыла башлаган Пушкин дәрьясын еллар үткән саен, үрелеп буй җитә алган чаклы күрә барам; Пушкин галәмен тану гомер буе дәвам итәр.

Хәзер Пушкинны үз газиз телемдә укып хозурланам. *(Ш. Галиев буенча)*

**Җавап:** шигъри, дөньясына, әүвәл, дәрьясын, галәмен, гомер, дәвам, хәзер, газиз, хозурланам.

*(табылган һәр сүз - 1 б.)*

**IV. Җөмләдәге тыныш билгеләренең ни өчен куелуын аңлатыгыз.** / Объясните, по каким правилам поставлены знаки препинания в предложении. (10 баллов)

Шуңа да игътибар итәргә кирәк:(1) Кол Гали дә,(2) Мөхәммәдьяр да "сабыр" сүзендә,(3) язмышка буйсынып,(4) пассивлык күрсәтүне түгел,(5) бәлки, (6) эшнең җаен белеп,(7)нигезле хәлдә гамәл итүне күздә тота.(8) (М. Госмановтан)

(1) Көттерү интонациясе белән бәйләнгән баш җөмлә алдан килсә, аннан соң ике нокта куела. (2 балл)

5 – каршы кую куючы теркәгеч алдыннан куела (2 балл)

3 һәм 4, 6- 7 нче өтерләр – аерымланган хәлләр янында куела. (4 балл)

8 – хикәя җөмлә ахырында нокта куела.

**V. Башваткычны чишегез.** / Решите кроссворд. (15 баллов)




**VI. Равил Фәйзуллинның шигыре килеп чыгарлык итеп, калын хәреф белән бирелгән сүзләрне җәя эчендә соралган рәвештә төрләндерегез һәм бер-берсенә бәйләгез** /Воспользуясь подсказками в скобках, склоняйте и свяжите выделенные слова таким образом, чтобы в итоге получилось четверостишие равиля Файзуллина. (15 баллов).

**__Җавап:__**

Киләчәкнең башы − бүгенгедә. (4 б)
Нинди шатлык картлык көнеңдә − (3 б)
Оныкларың сиңа рәхмәт әйтсә, (4 б)
Матур итеп туган телеңдә! (Равил Фәйзуллин) (4 б.)

**VII. Татар теленең орфографиясе һәм аның принциплары турында языгыз** / Напишите об орфографии татарского языка и о его принципах (15 баллов).

**__Җавап:__**

Татар теленең орфографиясе һәм аның принциплары

Әдәби телдә дөрес язу нормалары һәм кагыйдәләре җыелмасын орфография дип йөртәләр.

Татар орфографиясе берничә принципка нигезләнә:

Фонетик принцип. Бу - сүзләрне ишетелгәнчә язу дигән сүз, һәм ул безнең телдә төп принцип булып санала. Мәсәлән, кайчакта сүзгә кушымча ялганганда, сүзнең соңгы авазы үзгәрә, һәм ул язуда да күрсәтелә:

ак - агы    китап - китабы    кара - карабрак һ.б.

Морфологик принцип. Бу - сөйләмдә кулланганда, сүзләрнең кайбер авазлары үзгәрсә дә, аларны язуда, үзгәртмичә, беренчел морфологик төзелеше ничек булган, шулай язу дигән сүз. Мәсәлән, ун һәм бер сүзләре янәшә килсә, [умбэр] дип әйтелә, унбер дип языла; [һишшыксез] дип әйтелә, һичшиксез дип языла; [чәчәгата] дип әйтелә, чәчәк ата дип языла.

График принцип. Бу - алынма сүзләрне шул тел орфографиясендәгечә язу дигән сүз. Мәсәлән, татар телендә рус теленнән алынган сүзләр рус теле орфографиясечә языла: морфология, лексикология, эволюция, бизнес, менеджер...

Тарихи-традицион принцип. Бу - сүзләрне, хәзерге телдә ничек әйтелүенә карамастан, борынгы чорда ничек язылган, шулай язу дигән сүз: сурәт - [сурәт].

Экономия принцибы. Бу - язу барышында вакытка һәм урынга экономия ясау өчен, сүзләрне кыскартып язу дигән сүз. Телдә еш кулланыла торган һәм күпләргә таныш кушма атамалар андагы үзләрнең баш хәрефләрен генә язу юлы белән кыскарталар: Казан дәүләт университеты - КДУ, Берләшкән Милләтләр Оешмасы - БМО. Еш очрый торган сүзләр, атама булмаса да, кыскартылырга мөмкин: һәм башкалар - һ.б. Кайбер кушма атамаларда беренче сүзнең - баштагы өлеше, башка сүзләрнең баш хәрефе генә языла: КамАЗ, АлАЗ. Кушма сүзнең соңгысы - тулы килеш, баштагылары кыскартылып язылырга да мөмкин: драмтүгәрәк, райүзәк.

**VIII. Татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукай турында "Очты дөнья читлегеннән тарсынып күңелем кошы" дигән темага 80 сүздән ким булмаган инша языгыз.** /Напишите сочинение (не менее из 80 слов) на тему "Улетела птица моей души, презрев этот бренный мир" о великом татарском поэте Габдулле Тукай (20 баллов)

**Иншаны бәяләү критерийлары:**

1. Темага туры килү дәрәҗәсе *(темага туры килмәгән эшләр бәяләнми)*. - 2 б.
2. Темада чагылган проблеманы аргументацияләү осталыгы. Укучының алдан үзләштергән әдәби яисә фәнни материалны куллана алу дәрәҗәсе. - 6 б.
3. Иншаның композицион бөтенлеге һәм логик эзлеклелеге. - 4 б.
4. Укучының язма сөйләм сыйфаты (стиль ягы). - 4 б.
5. Грамоталылык. - 4 б.